## КАРАР №41

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советы утырышы

18 февраль 2022 ел

Комыргуҗа авылы

**Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" гы Федераль законга үзгәрешләр керү сәбәпле, Әтнә районы прокуратурасының 2022 елның 28 январендәге, 02-08-02/Прдп41-22 номерлы протестын карап һәм тикшереп, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 38 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Комыргуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 нчы бүлектәге 10.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасы өстәргә:
"9.1. чит ил гражданлыгын (подданлыгын) алу яки яшәүгә рөхсәт алу турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) яисә башка документ алу турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма чит ил гражданлыгы алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган документ турында язма рәвештә хәбәр итәргә";

1.2. 11 нче бүлекнең 11.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"6. Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданын (гражданлыгы) туктату, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы".

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф.Низамиев